СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение                                                                 Карар
13 июнь 2023 ел                                                       №2-23

Ишки авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы № 1-7 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы федераль законнар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы “Ишки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Ишки авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы № 1-7 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә ( 18 ноябрь, 2016 ел, № 2-14, 15 май, 2017 ел, № 1-21, 28 июль, 2017 ел, № 3-22, 05 июнь 2018 ел, №2-32, 13 август 2018 ел № 2-34, 20 ноябрь, 2018 ел, № 3-37, 21 март,2019 ел, № 1-40, 18 сентябрь 2019 ел №3-45, 19 февраль 2020 ел, №1-50, 22 июнь 2020 ел, №3-52, 17 ноябрь, 2020 ел, № 3-2, 10 июнь 2021 ел №1-9, 08 октябрь 2021 ел, №2-11, 22 ноябрь 2021 ел, №1-12, 22 июнь 2022 ел, №2-16,20 февраль 2023 ел, №5-21) карарлардагы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 6.3. пунктының 5 пунктчасында «, Район сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 7 статьясының 7.4 пунктында « муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе Аппараты», « муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 8 статьяның 8.1. пунктында:

1 пунктчаның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктчаның өченче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;
1 пунктчаның дүртенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;
3 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;
4 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;
5 пунктчада «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе», «, башка муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;
8 пунктчада «, «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм аларның җитәкчеләре» сүзләрен төшереп калдырырга;
4) 8.1. статьяда:
1 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;
4 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;
5 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;
10 пунктның 3 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратына» сүзләрен төшереп калдырырга;
) 9 статьяның 9.8 пунктында «Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга;
7) 12 статьяның 12.19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«12.19. Россия Федерациясе Хезмәт кодексында каралган хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигезләрдән тыш, муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсе шулай ук яллаучы (эш бирүче) вәкиле инициативасы буенча түбәндәге очракларда өзелергә мөмкин:
1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән иң чик яшькә җиткәч;
2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13, 14, 14.1 һәм 15 статьяларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәү;
3) дисквалификация рәвешендә административ җәза куллану;
4) муниципаль хезмәткәрләргә чит ил агенты статусы алу.
8) 13 статьяда:
13.9 пунктындагы «г» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«- законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр һәм (яисә) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яисә гражданның хезмәт (эш) эшчәнлеген раслый торган башка документлар (хезмәт (эш) эшчәнлеге элек башкарылмаган очраклардан тыш);»;
9) 22 статьяның 22.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«22.3. дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.».»;
10) Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

1 нче бүлектә:

1 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 нче бүлектә:

5 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 пунктның 4 пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратын» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 нче бүлектә:

15 пунктның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

21 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районыныңт Ишки авыл җирлеге башлыгы Р.К.Хафизовка йөкләргә.

Ишки авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы /Р.К.Хафизов/